**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы**
**11 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың җиде биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 180 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **50**. Уңышлар!

**1. Нинди сәнгати алым турында сүз баруын билгеләгез. (2 балл)**

- ул әдәби әсәрдә геройларның эчке дөньясын: фикерләрен, хисләрен, кичерешләрен һәм рухи халәтләрен ачып бирүгә юнәлтелгән;
- ул авторга герое гамәленең эчке сәбәпләрен аңлату, аң һәм аң төпкеленең катлаулы эшен күрсәтергә мөмкинлек бирә;
- аның аша язучы еш кына кеше табигатенең универсаль якларын өйрәнә, яшәешнең мәңгелек сорауларына ачыклык кертә.

_______________________________________________________

**2. Футуризм агымына хас булмаган 2 сыйфатны билгеләгез. (2 балл)**

а) агрессив-бунтарь шәхесне сурәтләү;

ә) тормышны хаос, тәртипсезлек рәвешендә күрсәтү;

б) кеше бизәкле һәм фаҗигалы дөнья реальлеген образлы күзаллый дип санау;

в) ямьсезлек эстетикасына йөз тоту;

г) үзәктә ялгыз шәхес концепциясе яту;

д) әдәби шартлылыктан баш тарту.

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (1 балл)**

___________________________________________

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (1 балл)**

а) Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында

ә) Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылы

б) Оренбург губернасы Эстәрлетамак өязе Җиргән авылы

в) Татарстанның Мөслим районы Олы Чакмак авылы

______________________________________________________________

______________________________________________________________

**3. Әлеге әдип турында дөреслеккә туры килмәгән фактны билгеләгез (2 балл)**

а) Ул 1925-1929 елларда Казан җир төзелеше техникумында белем ала.

ә) Шагыйрь нахак бәла күтәреп, дүрт ел төрмәдә утыра.

б) Әдип 2002 елның 13 мартында вафат була һәм Яңа бистә зиратына җирләнә.

в) 2025 елда шагыйрьгә Казанда һәйкәл ачыла.

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

**4. Колшәрифнең кайсы чор әдәбияты вәкиле булуын билгеләгез. (1 балл)**

а) Алтын Урда чоры әдәбияты.

ә) Казан ханлыгы чоры әдәбияты.

б) Торгынлык чоры әдәбияты (XVI гасырның II яртысы – XVIII гасыр).

в) Яңарыш дәвере әдәбияты.

______________________________________________________________

______________________________________________________________

**5. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын һәм жанрын билгеләгез. (9 балл)**

а) Төш, йолдызлар, аждаһа, сугыш, агу, үлем, мәхдүм.

___________________________________________________________

а) Пәке, йола, шәҗәрә, миләш агачы, Гөлйөзем әби, талак, ике каен.

___________________________________________________________

б) Кечкенә тәрәзә, миләш агачы, ак чыбылдык, ана, хат, хат ташучы, сугыш, Хәсән.

___________________________________________________________

**6. Хикәядән өзекне укыгыз.**

Бүген июньнең егерме сигезенче көне... Туганы аның һәр елны шушы числоларда яки июль башларында институттан кайта торган иде. Әнисенең, туганнарының сөеп, сокланып карауларына каршы ул һаман бер сүз белән, — гүя аңардан шуны гына сорыйлар, — җавап кайтара иде:

— Әни, зачётларымны башкалардан элек биреп бетердем, сезнең янга кайтырга ашыктым.

Былтыр исә ул институтны тәмам бетереп кайтырга тиеш иде. Ләкин өйгә, туганнары янына шундый зур шатлыкның бәйрәмен бергәләп үткәрер өчен кайтасы вакытта фронтка китеп барды. Ә өйдә аның бу кайтуын көтү әле һаман аларның йөрәкләрендә саклана. Һәрхәлдә, ана бүген, моны исенә төшереп, сүз кузгатмыйча калмас.

Кечкенә өй эче яңгыр белән юылып яшәргән көннең җылы яктылыгыннан киңәйгән кебек... Миләш агачының яфраклары аша төшкән кояш нурлары, өйнең идән-стеналарын эре-эре челтәрле бизәкләр белән чуарлап, тибрәнеп уйныйлар. Өстәлдәге графинның түгәрәк бөкесе, ачык шкафның тар шүрлегендәге киртләчләренә кыстырган балкашык башлары бу шаян, йөгерешкән нурларны үзләренә җыялар һәм үзләре дә кечкенә кояшчык шикелле тирә-юньнәренә күз камаштыргыч яктылык чәчеп балкыйлар... Куе-җиңел, хуш исле һава, өй эченә берьюлы мул булып керергә теләгәндәй, тәрәзәнең читләренә җыелган ак пәрдәне күтәреп-күтәреп куя һәм һәрнәрсәне иркәләп, сыйпап йөргән кебек тоела.

Ананың бүген кәефе яхшы. Бу шифалы һаваны сулавы аңа җиңел, рәхәт; зәгыйфь тәнендә, никадәр хәлсезләнгәнен сиздереп, ниндидер бер җылымса талгынлык йөри.

**Өзек буенча сорауларга җавап бирегез.**

**а) Әсәрнең исеме. (1 балл)** ________________________________________

**ә) Әсәрнең авторы. (1 балл)** ______________________________________

**б) Өзектә сүз кемнәр турында баруын билгеләгез. (1 балл) Әсәр героеның нинди хисләр кичерүен языгыз. (2 балл)**

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

**в) Өзектән**

- **метафорага мисаллар табып языгыз (1 балл)**

________________________________________________________

- **чагыштыруга мисаллар китерегез (4 балл)**

- **эпитетка мисаллар табып языгыз (7 балл)**

**7. Үзегез яратып укыган әдәби әсәрне, исемен күрсәтмичә, ләкин аны танырлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан әсәрнең исемен, авторын күрсәтегез. Күләме 10-12 җөмлә. (15 балл)**